ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«3» апреля 2024 ел    Шилнәбаш авылы    № 2

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге составына керүче Шилнәбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 10 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Шилнәбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 август 36/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге составына керүче Шилнәбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 10 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреля 19.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге составына керүче Шилнәбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ».

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 10 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылында гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Шилнәбаш авыл җирлеге, Шилнәбаш авылы, 60 лет Октября ур., 2 йорт .

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Шилнәбаш авыл җирлеге Башлыгы О.А. Чекушкова